## Балалар бакчалары җитәкчеләре РМО беркетмәсе № 2

**Үткәрү вакыты**: 29.11.2019
**Үткәрү урыны**: № 6 балалар бакчасы
**Катнашнашырга тиеш**: район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А. А., РМО җитәкчесе Аглямова М.В., балалар бакчалары мөдирләре, өлкән тәрбиячеләр.
**Катнашалар**: 42 бакча мөдире, 5 өлкән тәрбияче, РМО җитәкчесе Хаернасова В.М., район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А. А.

**Тема**: “Индивидуальное развитие ребенка в соответствии с ФГОС”

**Көн тәртибе:**

1. Ачык мероприятияләр карау. Анализ.
2. Эш тәҗрибәсе белән уртаклашу. Презентацияле чыгыш. Хаернасова В.М.- өлкән тәрбияче.
3. Төрлеләр.

**Утырыш барышы**:

1 нче көн тәртибе буенча практик эшчәнлек – шөгыльләр каралды.
Тәрбияче Ахатова Ф.Ф. 1 кечкенәләр төркеме белән “Куянга булышабыз” дигән темага шөгыль күрсәтте. Соңыннан максаты, бурычлары, балалар контингенты белән таныштырды. Ата-аналар белән эшләгән эшен күрсәтте.

Анализ:

- Теләкәй балалар бакчасы мөдире Гөлчәчәк апа: “Тәрбияче шөгыльне балаларның яшь үзенчәлеген исәпкә алып төзегән, балаларны активлаштырып тору өчен алымнарны күп алган. Балалар апаларын тыңлый беләләр, кызыксынып шөгыльләнәләр. ФГОС буенча бар өлкәнедә исәпкә алган.”
- № 4 балалар бакчасы өлкән тәрбиячесе Гумерова Л.: “Тема программадан чыгып алынган, шөгыль структурасы дөрес төзелгән, эш алымнарын кызыклы итеп алган. Балаларны активлаштырып торды. Сөйләм теле уздыру методикасы һәм структурасы сакланган” .

2 нче шөгыльне уртанчылар төркеме белән Шайхутдинова Ч.Т. “Витаминнар һәм аларның кеше тормышында әһәмияте” дигән темага сөйләм теле шөгыле күрсәтте. Максаты белән таныштырды, аңа ирешүен әйтте.

Анализ:

- Куян балалар бакчасы мөдире Имамова И.: “Шөгыль структарасы дөрес алынган, балаларга кызыклы булды, активлар, тәрбияче соравына теләп, тулы җөмләләр белән җавап бирәләр. Тәрбияче үзе артистлар кебек, эмоциональ”.
- № 4 балалар бакчасы өлкән тәрбиячесе Мөршидә апа.: “Тәрбияче системалы эшли, балалары күп белә, матур сөйләшәләр. Һәр баланың фикерен әйтеп бетерүен тыңлый. Шөгыльдә әхлаклылык тәрбиясе күтәрелде”.

3 шөгыльне зурлар төркеме белән тәрбияче Насрыева Л.Н. “Айболитка ярдәм итәбез” дигән темага күрсәтте. Максаты, бурычы белән таныштырды. Балалар коллективы белән таныштырды. Үзанализ ясады.

Анализ:

- Такталачык балалар бакчасы мөдире Лира апа: “Тәрбияче максатына иреште. Шөгыльне башыннан азагына кадәр бәйләнешле,эзлекле итеп алып барды. Алдан күп эшләнгән, күп материал алынган, шөгыль катлаулы булсада балалар армадылар, кызыксынып шөгыльләнделәр.”.
- № 7 балалар бакчасы өлкән тәрбиячесе Нуриахметова А.: “ФГОСның бөтен өлкәсе дә алынган, бер-берсенә бәйләнеп баралар. Тәрбияче кирәкле материалны алдан әзерләп куйган.

2 көн тәртибе буенча балалар бакчасы өлкән тәрбиячесе Хаернасова В. “Индивидуальное развитие ребенка в соответствии с ФГОС” дигән темага презентацияле чыгыш тәгъдим итте. Педагоглар сорауларына җавап бирде.

3 көн тәртибе буенча Айгуль Азатовна сүз алды:

- Ел тәрбиячесе конкурсына заявкаларны биреп бетерергә; шөгыльләрне һәм самопрезентацияләрне положение нигезендә структурасын сакларга.
- Ел азагы отчет формалары куелды (85К, 85УП), график нигезендә килүегез сорала;
- Ел азагына рейтингка күрсәткечләрне җыярга, подтверждениеләрен дә теркәргә;
- Яңа ел бәйрәмнәре күчтәнәчләре өчен балалар исемлекләрен формалаштырып китереп бетерергә;
- Бәйрәмнәрне 25 декабрьдән дә иртә уздырмаска һәм бәйрәмнәр уздыру буенча инструктажларны сакларга;
- О внесении изменений в Постановление ИК АМР от 01.11.2019 г. № ПР-255 «Об утверждении нормативных затрат общеобразовательных организаций муниципального образования Актанышского муниципального района
на 2020 год»;
Постановление от 18.12.2019 №ПР-316 О внесении изменения в Постановление исполнительного комитета Актанышского муниципального района от 23.09.2013 г. №ПР-657 "О предоставлении мер социальной поддержки гражданам, имеющим детей , посещающих образовательные организации, реализующие образовательную программу дошкольного образования." Постановлениеләрен өйрәнеп, ата-аналар җыелышлары җыеп ата-аналарга яңача түләү турында аңлатырга, өстәмә соглашениеләр төзергә.

Карар:

1. Бала белән индивидуаль эшчәнлектә № 6 балалар бакчасының тәҗрибәсен өйрәнеп үрнәк итеп алырга.
2. Статотчетларга әзерлек белән килергә.
3. Югарыда әйтлгән постановлениеләрне өйрәнеп ата-аналарны да таныштырырга

Район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист : ___________ Ахтямова А.А.
РМО җитәкчесе: _________ Аглямова М.В.
Сәркатип: ____________ Шакурова Р. Д.